ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«22» февраль 2024 ел №145

**2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы, «2024 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативы һәм 2024 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2023 елның 11 декабрендәге 888/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясен билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 18 августындагы 584/пр номерлы боерыгы, «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак бирү һәм исәпкә куелганда торак мәйданы нормативлары турында» Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 маендагы 311 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме 22059,00 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен- 865278,00 сум;
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1730556,00сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен-2595834,00 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен- 3461112,00 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен- 4326390,00сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен-5191668,00 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен-6056946,00 сум;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 6922224,00 сум
1.1.9. Тугыз кешелек гаилә өчен-7787502,00 сум;
1.1.10. Ун кешелек гаилә өчен-8652780,00 сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгының торакны исәпкә алу һәм бүлү буенча урынбасары С.С. Гатауллинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*22.02. 2024 ел, №145*
*карарына кушымта*

**2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече (алга таба-исәп күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП Х РС х РЦ,

биредә:

СЖ-социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урыны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен башкарма хакимиятнең тиешле федераль органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның уртача базар бәясеннән артмый торган уртача исәп бәясе.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 48071,00 х 18 = 865278,00 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х18 х 2 = 1730556,00 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х 18 х 3 = 2595834,00 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 8071,00 х 18 х 4 = 3461112,00 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х 18 х 5 = 4326390,00 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х 18 х 6 = 5191668,00 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х 18 х 7 = 6056946,00 сум

3) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 48071,00 х 18 х 8 = 6922224,00 сум

и) тугыз кешедән торган гаиләгә: 48071,00 х 18 х 9 = 7787502,00 сум

к) ун кешедән торган гаиләгә: 48071,00 х 18 х 10 = 8652780,00 сум.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәп күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма

керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) СЖ исәп бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, торак урыны алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә (ул гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнә):

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1) (1 + ПС) / (0,25 х РС),**

биредә:

ПД-гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ-исәп күрсәткече;

ПС - кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма), (Россия Федерациясе Үзәк банкы ставкасы елына 7 %, ягъни аена 7/100/12 аена=0,006(«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында "2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алга таба чаралар турында" 02.08.2007 № 366 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә);

КП -бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС-гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләү һәм гаиләнең айлык җыелма кереме нисбәте;

"Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге"нең "Бәяләр диапазонын билгеләү турында" 2024 елның 19 гыйнварындагы 06 номерлы хаты нигезендә 2024 елда Арча муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 48071,00 сум тәшкил итә.

**Һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү**

1нче табл.

| НП-торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ-торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ Х НП) (сум.) | РС-гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ-1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум.) | Кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | Кредит буенча түләү белән айлык җыелма керем нисбәте | ПД - максималь керем (сум (гаиләгә) | Максималь керем (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | |
| | 865278,00 | | 48071,00 | 7/100/12 =0,006 | 180 | 0,7 | 0,25 | | |
| 18 | 865278,00 | 1 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 0,25 | 22059,00 | 22059,00 |
| 36 | 1730556,00 | 2 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 0,50 | 44118,00 | 22059,00 |
| 54 | 2595834,00 | 3 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 0,75 | 66177,00 | 22059,00 |
| 72 | 3461112,00 | 4 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 1,00 | 88236,00 | 22059,00 |
| 90 | 4326390,00 | 5 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 1,25 | 110295,00 | 22059,00 |
| 108 | 5191668,00 | 6 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 1,50 | 132354,00 | 22059,00 |
| 126 | 6056946,00 | 7 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 1,75 | 154413,00 | 22059,00 |
| 144 | 6922224,00 | 8 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 2,00 | 176472,00 | 22059,00 |
| 162 | 7218882,00 | 9 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 2,7 | 198531,00 | 22059,00 |
| 180 | 8652780,00 | 10 | 48071,00 | 0,006 | 180 | 0,7 | 3,0 | 220590,00 | 22059,00 |